ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.12.2018 г. Заинск № 1476

**«2019 елга «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында»**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Татарстан Республикасы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2013 елның 30 декабрендәге 1096 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә , Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2019 елга кушымта итеп бирелгәнне расларга:

«Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карап тоту һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар;

«Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең күләме.

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесен тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пункты белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын финанслау нормативлары нигезендә мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын финанслау.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

3. Башкарма комитетның оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районы массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет

җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А. В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Г.М. Зиганшина
3-52-91